**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“10” ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Үртәм торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Үртәм торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1000 (бер мең)сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Үртәм авылындагы су башнясы будкасы өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- тимер-бетон боҗраларны сатып алу һәм урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Үртәм авылында зиратны койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары алу, хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Үртәм авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.